РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«14» февраль, 2023 ел Олы Кайбыч ав. № 169

Кайбыч муниципаль районының 2022 елгы социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2023 елга бурычлары турында

Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И. Рәхмәтуллинның «2022 елда социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2023елга бурычлар турында» хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, Кайбыч муниципаль районы Советы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының үз вәкаләтләрен башкарганда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары, Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә эш итүен билгеләп үтә. Хисап чорында муниципаль районның җирле үзидарә органнары икътисадны һәм социаль өлкәне тотрыклы үстерүгә ирешүгә, район тормышын тәэмин итүнең барлык системаларының тотрыклы эшләвенә, район халкының лаеклы тормыш дәрәҗәсен тәэмин итүгә, милләтара, динара һәм гражданлык татулыгын ныгытуга, җирле үзидарәне үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән эзлекле сәясәт алып бардылар. Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Кайбыч муниципаль районының алга таба нәтиҗәле социаль-икътисадый үсеше, 2023 елга бурычларны уңышлы гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллинның «2022 елда социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре һәм 2023 елга бурычлар турында» хисабын игътибарга алырга.

2. Кайбыч муниципаль районы Советы депутатларына 2022 елда Кайбыч муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2023 елга бурычлар турында хисапны үз округларында сайлаучылар игътибарына җиткерергә.

3. Район Советы Аппаратына хисап докладында һәм аның турында фикер алышканда әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына:

- 2023 елның 15 мартына кадәр хисап докладында һәм аның буенча фикер алышканда әйтелгән искәрмәләр һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга;

- районның икътисад һәм социаль өлкәсе секторларын, сәнәгать мәйданчыкларын үстерү һәм гамәлдәге инвестиция проектларын гамәлгә ашыру буенча эшне дәвам итәргә;

- тотрыклы социаль-икътисадый хәлне саклап калу максатында икътисад тармакларын үстерү чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

- яңа инвестиция проектлары перспективасы буларак М-12 трассасын төзи башлауга аерым игътибар бирергә;

- муниципаль район территориясендә законлылыкны һәм хокук тәртибен саклауны тәэмин итү эшен дәвам итәргә, балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия, хезмәткә сәләтле кешеләр арасында эчкечелекне һәм алкоголизмны профилактикалау эшен активлаштырырга;

- районның инфраструктур үсеше буенча эшне дәвам итәргә (юллар челтәрен, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү);

-административ регламентлар нигезендә муниципаль хакимиятнең башкарма органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтүне тәэмин итәргә;

- 2023 елга район бюджетының керем өлешен үтәүне тәэмин итәргә;

- белем бирү сыйфатын республика дәрәҗәсеннән  ким булмаган дәрәҗәгә күтәрергә һәм Бөтенроссия һәм республика олимпиадалары призерлары санын арттырырга;

- район территориясендәге спорт объектларының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итәргә, спорт түгәрәкләре һәм спорт - ял итү чаралары санын арттырырга;

- балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә ярдәм итәргә, яшьләрне җирле дәрәҗәдә социаль, икътисадый һәм иҗтимагый бурычларны хәл итүгә җәлеп итәргә;

- туучылар санын арттыруга, үлүчеләр санын киметүгә, гомер озынлыгын үстерүгә, шул исәптән медицина ярдәменең һәркем файдалана алырлык булуын арттыруга, аның профилактик юнәлешен үстерүгә, кан әйләнеше системасы авырулары, яман шешләре булган затларга медицина ярдәме күрсәтү системасын камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралар планын гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә. Шулай ук сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, сәламәт туклануны популярлаштыруга һәм системалы рәвештә физик культура белән шөгыльләнүче гражданнар санын арттыруга юнәлдерелгән чараларга да игътибар итәргә кирәк.

5. Кайбыч муниципаль районы Контроль-хисап палатасына:

- районның бюджет акчаларыннан һәм муниципаль милек объектларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшереп торуны көчәйтергә;

- контроль чаралар барышында коррупция күренешләре куркынычларына дучар булган өлкәләргә аерым игътибар бирергә;

- социаль әһәмияткә ия  өлкәләрдә җирле бюджетлар акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрергә;

- җир һәм финанс ресурсларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалану мәсьәләләренә зур игътибар бирергә.

6. Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына:

- М-12 трассасын төзү проектына аерым игътибар биреп, җир кишәрлекләреннән максатчан файдалануны контрольдә тоту эшен көчәйтергә;

- ай саен җир һәм муниципаль мөлкәт өчен аренда түләүләре бурычы мониторингын уздырырга;

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән законсыз файдалану очракларын ачыклау эшен дәвам итәргә;

- районның һәр авыл җирлегендә хуҗасыз йортларны һәм җир кишәрлекләрен теркәү эшләрен төгәлләргә.

7. Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына муниципалитетның федераль һәм республика программаларында өлешле катнашындагы чыгымнарны финанслауга өстәмә керемнәр хисабына район бюджетында финанс чараларын карарга.

8. Кайбыч муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына:

- авыл җирлекләре Советлары утырышларында Кайбыч муниципаль районы Башлыгының «2022 елда Кайбыч муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре һәм 2023 елга бурычлар турында» хисабы хакында фикер алышырга һәм хисап докладында әйтелгән искәрмәләр һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә;

- Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы белән берлектә авыл җирлекләре территориясендә җирләрне теркәүне төгәлләргә, буш җирләрне кадастр исәбенә куярга

- хуҗасыз җирләрне теркәү хисабына индивидуаль-торак төзелеше өчен җир кишәрлекләре резервын төзүгә ирешергә;

- аерым авыл җирлекләре өчен кирәк булган генераль планнарны эшләүне тизләтергә;

- авыл җирлекләре территорияләрендә, гаилә фермаларында һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларда кече һәм урта бизнесны үстерүгә ярдәм итәргә;

- торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту, экологик иминлекне тәэмин итү, авыл җирлекләре территорияләрендә рөхсәтсез чүплекләрне бетерү эшләрен дәвам итәргә;

- барлык авыл җирлекләре территорияләрендә каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм чыгаруны оештыру эшен дәвам итәргә;

- үзара салым буенча гражданнар җыеннары карарларын үтәүне активлаштыруга, халыкны җирле үзидарәдә катнашуга җәлеп итүгә юнәлтелгән чараларны дәвам итәргә;

- гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм алу эшен активлаштырырга;

- М-12 трассасын төзү һәм объектларда эшләр алып баруның барлык этапларының катгый законлылыгына ирешү белән бәйле чараларда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

9. Мобилизацияләнгән гражданнар гаиләләренә төрле яклап ярдәм күрсәтү буенча масштаблы чараларны, шулай ук махсус хәрби операция уздыру зонасына гуманитар ярдәм җыю һәм җибәрүне дәвам итәргә.

10. 2023 елны - Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы дип игълан итәргә.

Россия Федерациясендә Педагог һәм остаз елы һәм Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы кысаларында масштаблы чаралар үткәрергә

11. Әлеге карарны Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

12. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Рәис А.И. Рәхмәтуллин